**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 март № 162

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торганн дәүләт хезмәтләре сыйфаты стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 19 июнь, 525 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 666 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына,», «Татарстан Республикасының Баш ветеринария идарәсенә,» сүзләрен төшереп калдырырга, «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына,» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына» сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 декабрь, 1095 нче; 2012 ел, 19 июнь, 525 нче, 2012 ел, 20 декабрь, 1107 нче; 2015 ел, 15 сентябрь, 666 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына,», «Татарстан Республикасының Баш ветеринария идарәсенә,» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфаты Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килү-килмәүне бәяләү тәртибендә:

2.3 нче пунктның 2.3.4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.4. Контроль чараларын үткәрү нәтиҗәләре:

контроль чаралары тәмамланган көннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының рәсми сайтында урнаштырыла;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан раслана торган ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең эш сыйфатын күтәрү буенча чараларның ведомство планнарында исәпкә алына.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\162.docx